Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы

Питрәч муниципаль районы Советының дүртенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

25 ноябрь, 2020 ел № 25

2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Питрәч муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фаразы турында

Район икътисадын тотрыклыландыру һәм алга таба үстерү, муниципаль милектән файдалануның нәтиҗәлелеге, шулай ук халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрүне тәэмин итә торган шартлар булдыру өчен, «2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына Питрәч муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше фаразы турында» мәгълүматны тыңлаганнан соң, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. 2020 елда Питрәч муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенең башлангыч нәтиҗәләре турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Кушымта нигезендә, Питрәч муниципаль районының 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразын хупларга.

3. Тәкъдим итәргә:

- Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына, барлык милек формасындагы предприятие һәм оешма җитәкчеләренә 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына социаль-икътисадый үсешнең төп күрсәткечләрен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән тиешле чаралар күрергә;

- Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының икътисад бүлегенә квартал саен 2021 елга фаразны тормышка ашыру мониторингын тормышка ашырырга, мониторинг нәтиҗәләрен Питрәч муниципаль районы Советына җибәрергә.

4. Әлеге карарны Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Советының икътисади үсеш, бюджет, салымнар һәм финанслар мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И. М. Кашапов

Питрәч муниципаль районы
Советы карарына кушымта
25 ноябрь, 2020 ел № 25

Питрәч муниципаль районының 2018-2020 елларга социаль-икътисадый үсешенең төп күрсәткечләре
һәм 2021-2023 елларга фараз

| Күрсәткечләр | 2018 ел хисап | 2019 ел хисап | 2020 ел хисап | Фараз | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел |
| **Макроикътисади күрсәткечләр** | | | | | | |
| 1. Тулаем территориаль продукт, млн. сум. | 10771,8 | 11412,8 | 11526,9 | 12371,6 | 13265,01 | 14223,3 |
| 2. «Житештерүче һәм эшкәртүче сәнәгать» икътисади эшчәнлекнең номумроссия төрләр классификаторы (ОКВЭД) буенча үзе житештергән товарлар йөкләтелде, млн. сум. | 3519,3 | 3630,9 | 3801,54 | 4122,92 | 4480,82 | 4808,88 |
| 3. Инвестицияләр күләме (төп капиталга) һәр елның гамәлдәге бәяләрендә, млн. сум. | 11017,7 | 16607,1 | 16610,1 | 18434,88 | 20421,1 | 22621,2 |
| 4. Ваклап сату товар әйләнеше, млн. сум. | 3052,0 | 3250,60 | 3196,3 | 3457,1 | 3696,1 | 3951,5 |
| 5. Хезмәт хакы фонды, млн. сум. | 2725,0 | 2963,14 | 2915,73 | 3076,09 | 3279,12 | 3488,98 |
| 6. Даими халык саны (уртача еллык), мең кеше. | 38,42 | 42,61 | 47,21 | 49,70 | 51,80 | 53,90 |
| **Тормыш дәрәҗәсе** | | | | | | |
| 1. Җан башына акчалата керем, сум. | 19182,9 | 21447,80 | 21083,2 | 21715,7 | 22150 | 22725,90 |
| 2. Уртача айлык хезмәт хакы (бер елга уртача). | 30598,3 | 33110,9 | 32562,0 | 34183,4 | 36241,3 | 38306,7 |
| 3. Пенсиянең уртача күләме, аена сумнарда | 12474,5 | 13315,3 | 13981,11 | 14903,85 | 15798,16 | 16745,96 |
| 4. Үз керемнәре белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе, % | 51,6 | 54,3 | 52,7 | 55,0 | 57,0 | 58,0 |
| 5. Финанслауның барлык чыганаклары исәбеннән торак йортларны файдалануга кертү, кв.м | 139914 | 180000 | 210000 | 190000 | 200000 | 210000 |
| **Агросәнәгать комплексы** | | | | | | |
| Авыл хуҗалыгының тулаем продукциясе гамәлдәге бәяләрдә, млн. сум. | 3857,03 | 3948,96 | 4140,01 | 4387,6 | 4654,49 | 4961,44 |
| Авыл хуҗалыгы продукциясенең төп төрләрен җитештерү: | | | | | | |
| - ашлык (эшкәртелгәннән соңгы авырлыкта), мең тонна | 64,66 | 68,6 | 91,3 | 94,0 | 94,2 | 94,5 |
| - бәрәңге, мең тонна | 2,45 | 1,4 | 0,3 | 0,5 | 0,5 | 0,5 |
| - терлек һәм кош (тере авырлыкта), мең тонна | 33,54 | 34,0 | 34,2 | 35,2 | 35,7 | 36,4 |
| - сөт, мең тонна | 21,465 | 21,015 | 22,3 | 22,9 | 23,6 | 24,0 |
| - йомырка, млн. данә | 41,7 | 42,8 | 41,6 | 42,8 | 43,2 | 43,5 |

Питрәч муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Хәбибуллин